**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2023 елның 28 феврале 25-РСномер

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлегенең генераль планын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Куюково авыл җирлегенең 2023 елның 2 февралендәге 10-53/1142 номерлы генераль планы проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсен карап, 2023 елның 2 февралендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне карап, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлегенең генераль планы проектын (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган)көннән үз көченә керә.
4. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Куюково авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» 2017 елның 11 декабрендәге 79-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарын әлеге карар үз көченә кергән вакыттан үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык - муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**